БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июнь 2018 ел № 132

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проектын 1 нче кушымта нигезендә хупларга һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.
2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Балтач ш.т.п., Ленин урамы, 42 нче йорт, 3 кат. Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 2018 елның 29 июне 13.00 сәгатьтә.
5. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы
рәисе урынбасары Н.Н.Сабирҗанов